**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нче йорт. Тел.3-02-22. Факс 3-13-44

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
12.09.2019 ел.

К А Р А Р
ПР-187

**Башкарма комитет җитәкчесенең "Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товар белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турындагы Нигезләмәне раслау хакында " 2018 елның 5 апрелендәге ПР-65 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2013 елның 5 апрелендәге ФЗ-44 номерлы "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" гы Федераль законны үтәү йөзеннән, бюджет һәм бюджеттан тыш акчаларны нәтиҗәле файдалану, намуслы көндәшлекне үстерү, кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштырганда ачыклык һәм үтә күренмәлелекне тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының "Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товар белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча Бердәм комиссия турындагы Нигезләмәне раслау турында " 2018 елның 5 апрелендәге ПР-65 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмати телекоммуникация челтәрендә һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында" бастырып чыгарырга.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 мартындагы ПР-73 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л. Ф. Нурлыева

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
12.09.2019 г. №ПР-187

1 нче санлы кушымта

Актаныш муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товар белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны һәм башкаручыларны) билгеләү буенча бердәм комиссия составы

| | |
|---|---|
| Шакирова Алия Миндыгали кызы | Комиссия рәисе, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы |
| Ризванова Рәйлә Салават кызы | Комиссия рәисе урынбасары, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы урынбасары |
| Митрофанова Айгөл Рифкать кызы | Комиссия секретаре, баш белгеч |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гарипов Руслан Илус улы | Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары |
| Сәлимов Дилфат Зөлфәт улы | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| Галимәрданова Алисә Ансаф кызы | Актаныш муниципаль район советының бухгалтер исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы |
| Абударов Фәндүс Индус улы | "УКС" МУП директоры |